

Сынатмаслар затыннан ул.Тормышта табигый байлыкнын асылташы булган кебек, торле һонәр ияләре арасында осталарынын остасы, һәркем vрнәк алырдай талантлысы була. Алар башкалардан аерылып та тормыйлар, ләкин vзләренен намуслы хезмәтләре, булдык-лылыклары белән vзеннән-vзе танылалар. Кvркәм табигатьле Инсар районы Большие Поляны авылында доньяга килеп, шунда туып-vскән, бvгенге кондә дә анда яшәvче Адилә Закир кызы Альмяшева - нәкъ шундыйларнын берсе.

Оясында ни кvрсә, очканында шул булыр дигәндәй, гаиләдәге татулык һәм эшсоярлек ике кызга - Адилә белән Розага да кvчә. Гомере буе  хужалыкта кайнаган әти-әнисе жиргә, авыл тормышына мәхәббәт хисе тәрбияләгәнгә кvрә, һәр эшне яратып, жиренә житкереп башкарырга кvнегәләр кызлар, хезмәттә чыныгып vсәләр.       Адилә Закир кызы Большие Поляны гомуми белем биргән урта мәктәптә белем алганнан сон, М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институтынын филология факультетына укырга юллана. Бередә ул гел яхшы билгеләргә генә укый, башкалар белән уртак тел таба белvе, оста телле, жыр-монга гашыйк булуы аркасында, һәрвакыт бик кvп дуслар таба. М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институтында бик әйбәт билгеләренә югары белем алгач, Инсар шәһәренен беренче номерлы балалар бакчасында мактаулы тәрбияче булып утыз ел хезмәт итә. Бар яклап булдыклы, белемле, кин эрудицияле, даими эзләнvче, vз остендә бертуктаусыз эшләvче белгеч буларак тәрбияче балалар арасында - ярату, әти-әниләре арасында – хормәт яулый.  Кvпьеллык фидакарь хезмәте бәяләнми калмый, ана республика, район тарафыннан бирелгән Мактау грамоталары да бихисап.

Адилә Закир кызы Альмяшева турында унган хатын диләр. Туганнарын, балаларын vз канаты астына жыеп, туган авылында ярдәмләшеп, тату гомер кичерә  юбиляр. Балалары Регина белән Ринатка яхшы тәрбия бирә һәм алар тормышта унышлылар. Алар бvген vзләре дә әти-әниләр; Владик, Сабир, Ясмина, Даниил балаларын тәрбияләп vстерәләр. Әниләре алар белән хаклы горурлана. Дvрт оныгына кадерле әбәй дә ул. Мәрхәмәтлелеген әйтеп тә торасы юк Адилә Закир кызынын. Жиде ед урында яткан авыру әнисен, аннары әтисен тәрбияли.

Адилә Закир кызы жырлый да, бии дә, шигырь дә оста сойли; концертларнын

ценарийларын тозеп конферансье дә була. Авыл бәйрәмнәрен алып бара. Кече яшьтән жыр-монга гашыйк ул. Мәктәптә, ВУЗда укыганда анын катнашыннан башка бер генә музыкаль кичә дә узмый булган, бу юнәлештә кvпторле конкурсларда катнашкан. Балалар бакчасында эшләгән вакытта да торле-торле чараларда актив булган, ә бvген Иса авылы мәдәниятын баета: “Асылъяр” ансамбле житәкчесе. Гомер козенә якты омет-хыяллар, кvнел тулы назлар, тормышка мәхәббәт белән аяк басуы белән бәхетле ул. 11 август конне Адилә Закир кызынын Юбилее, ана 55 яшь тула. Аны кайнар котлап изге теләкләр тормыш иптәше Рафаэль, оныклары белән балалары, Роза сенелесе гаиләсе белән, кайнанасы Надия, дуслары телиләр.
Кадерлебез!
Бәйрәмен матур коннәр, изге хәбәрләр, шатлыклы яналыклар гына алып килсен. Бvгенге шат, сәламәт, бәхетле елмаюын сине беркайчан да ташламасын. Һәрчак шулай саф кvнелле сердәшче, тугры ярдәмче, vз һонәрен яхшы белгән хезмәт олгесе булып озын-озак еллар яшәвенне телибез. Сәламәтлек,  жан-тән тынычлыгы һәм бәхетләр сина ихлас кvнелдән!

**Роза Уторова**